**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«11» апрель 2024 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 22.11.2023 ел, № 7 карарның 1 пунктына аны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылында теркәлгән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Рус Әмзәсе торак пунктында ВНБ территориясен әйләндеп алу).

Халык җыенында рәислек итүче: Ә .Ф.Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина